РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» декабрь 2024 ел г. Альметьевск № 4109

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның савым сыерлары һәм (яисә) таналар сатып алуга һәм аларны тотуга,үз хуҗалыгында 3 һәм аннан күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны индивидуаль саву җайланмалары белән тәэмин итүгә бер һәм аннан да күбрәк баш савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы гражданнарны азык (печән, салам, фураж, ашлык фуражы, премикслар) белән тәэмин итүгә киткән чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында" 2023 елның 29 ноябрендәге 7147 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы, «2023 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру һәм кече хуҗалыкларны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2023 елның 25 сентябрендәге 3507 номерлы карары нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның савым сыерлары һәм (яисә) таналар сатып алуга һәм аларны тотуга,үз хуҗалыгында 3 һәм аннан күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны индивидуаль саву җайланмалары белән тәэмин итүгә бер һәм аннан да күбрәк баш савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы гражданнарны азык (печән, салам, фураж, ашлык фуражы, премикслар) белән тәэмин итүгә киткән чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 7147

заказ № 1-851

номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 19 ноябрендәге 3681 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарга 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«29» ноябрь 2023 ел №7147
карары белән расланган
2 нче кушымта

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның савым сыерлары һәм (яисә) таналар сатып алуга һәм аларны тотуга,үз хуҗалыгында 3 һәм аннан күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны индивидуаль саву җайланмалары белән тәэмин итүгә бер һәм аннан да күбрәк баш савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы гражданнарны азык (печән, салам, фураж, ашлык фуражы, премикслар) белән тәэмин итүгә киткән чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү турында карар кабул итәргә вәкаләтле комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| Каюмов А.М. | - | комиссия рәисе, район башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары; |
| члены комиссии: | | |
| Мөхәммәтҗанов Р.Р. | - | «Әлмәт район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы (килешү буенча); |
| Шәрәфиев Ф.М. | - | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Әлмәт муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Шаргина И.Н. | - | район башкарма комитетының авыл җирлекләренең социаль инфраструктурасын үстерү секторы мөдире; |
| Авыл җирлекләре башлыклары | - | килешү буенча.» |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 18 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе Г.М. Хәбутдинова